СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

---

**Решение** | **Карар**

от “15 ” мая 2017 г. | № 2-22

Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге Советының 2011 елның 28 мартындагы «Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле калдыкларны җыю, алып китү, утильләштерү һәм эшкәртү тәртибен раслау турында» 1-8 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Мамадыш районы прокурорының 2017 елның 15 мартындагы җитештерү һәм куллану калдыклары турында законнарны бозуларны бетерү турында №02-08-03-2017 номерлы күрсәтмәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2011 елның 28 мартындагы «Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле калдыкларны җыю, алып китү, утильләштерү һәм эшкәртү тәртибен раслау турында» 1-8 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып игълан итәргә.

3. 3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башлыгы А.Я.Ильинга йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге Советы рәисе ____________ / А.Я.Ильин /